Татарстан Республикасының
Алабуга муниципаль районының 27 нче
“Миләшкәй”
балалар бакчасы мәктәпкәчә гомуми
үсеш һәм муниципаль бюджет белем
бирү учреждениясе

Муниципальное бюджетное дошкольное
образовательное учреждение детский сад
№27 “Рябинушка”
общеразвивающего вида
Елабужского муниципального района
Республики Татарстан



# “Әбиемнең серле сандыгы”

**Воспитатели: Камалова Л. М.**
**Идрисова Г. Ф.**

# Бурычлар:

1. Балаларда татар милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну уяту, аларның үзләренә генә хас булган нәфис бизәлешенә, уңайлылыгына соклану хисләре, матурлыкны күрә һәм аны саклый белү сыйфаты, зәвыклылык тәрбияләү.

2. Халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру: сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү.

3. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә куллануны системалаштыру.

# ӘБИЕМНЕҢ СЕРЛЕ САНДЫГЫ




30

***Әбиемнең күңел сандыгы!***
***Нинди серләр саклый икән ул?***
***Гомер буе җыйган хәзинәме,***
***Әллә инде күңел бизәгеме,***
***Нинди серләр саклый икән ул?***
***Әбиемнең күңел сандыгын***
***Бер ачасы иде, ачасы...***
***Әби-бабам белгән йолаларны,***
***Халкыбызның күңел җәүһәрләрен***
***Бер ачасы иде, ачасы.***
***Әбиемнең матур сандыгы***
***Кызыктыра инде күптәннән.***
***Ач, әбием, безгә күңелеңне,***
***Яшь буынга мирас булып калсын,***
***Бер хәзинә калсын үткәннән.***

Әбиемнең сандыгында
Сакланмый ниләр генә.
Әйдәгез, сорыйк үзеннән,
Ачып күрсәтсен безгә.

Каян аңлап алды икән
Әби безнең теләкне? –
Түрдә торган сандыгын ул
Үзе ачып күрсәтте.







# КАЛФАК

*Җырлый-җырлый сәхнәләрдә*
*Аларның биер чагы.*
*Кызларга бик килешә башындагы...*(калфагы).
*Бәрхетләрдән тегелгән,*
*Ука белән чигелгән;*
*Нәкышләре көмешләргә,*
*Алтыннарга ку[illegible]н.*







# ТҮБӘТӘЙ

Әнием, ак сәйлән тезеп,
Чиккән яшел бәрхетне.
Бар түбәмдә ...(түбәтәем),
Мин бүген бик бәхетле.
Балкып тора түбәтәйләр
Энҗе бөртекләр белән.
Алар монда килгән гүя
Чын әкият иленнән.









# ЧҮӘК – ЧИТЕК

Яңа гына идем итек,
[Ч] өстәгәч,
Булдым ...(читек).
Бизәк төшкән итекләрне
Читекләр дип йөрткәннәр.
Аларны татар кызлары
Бәйрәмнәрдә кигәннәр.











# ЧИГЕЛГӘН ӘЙБЕРЛӘР

**Татар хатын-кызларыбыз**
**Эшнең серен белгәннәр.**
**Кич утырып, җырлар җырлап**
**Оста чигү чиккәннәр.**
**Бу сөлгеләр, эскәтерләр**
**Тамбур белән чигелгән.**
**Әллә инде өсләренә**
**Чын чәчәкләр сибелгән.**











# БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕ

*Чың-чың итеп чыңлыйлар*
*Толымнарда чулпылар.*
*Иңбашына хәтле төшкән*
*Матур көмеш алкалар.*




















# САБА

*Яр астындагы балчыктан*
*Чүлмәкләр ясап карыйм.*
*Аннары мичтә кыздыргач,*
*Сөт салырга да ярый.*
*Чәчәкле үсемлек яткан*
*Тәлинкә уртасына.*
*Бер ягына бөккән куйыйк,*
*Өчпочмак – яртысына.*













# КИЕМНӘР

Әби ничек матур итеп
Киенгән яшь чагында...
 - Бу бит минем туй
күлмәгем,
Бабаеңа чыкканда.
Күкрәктә изү-бизәге,
Әллә бабай бүләге?
Диңгез суы кебек тора –
Дулкынлана итәге...











Бу байлыкны урнаштырып,
Әби сандыгын япсын.
Безнең кебек балаларга
Тагын ачып күрсәтсен.

Бу чигешләр, бу бизәкләр
Килә ерак чорлардан.
Үсә татар балалары
Илһам алып шулардан.

# Кулланылган әдәбият:

1. Туган телдә сөйләшәбез: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек / Төз.: З. М. Зарипова, Л. Н. Вәҗиева, Р. С. Зөфәрова һ.б. – Казан: ФОЛИАНТ, 2012.

2. Әбиемнең сандыгы.

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ

